# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“15” ноябрь 2025 ел. № 1

« Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 14 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, 2025 елның 15 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта

«Сез 2026 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү. (Чишмәле Сап авылында чишмә ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

2) Коеларны төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Чишмәле Сап авылында коены ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

Сез, 2024 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын, түбәндәге җирле сорауларны чишүгә юнәлтергә ризамы:

3) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

(Чишмәле Сап авылында һәйкәл территориясен яшелләндерү (яшел утыртмалар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); (Чишмәле Сап авылы балалар мәйданчыгын төзкләндерү (җиһазлар, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); Чишмәле Сап авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

“РИЗА” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 211 (ике йөз унбер) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 113 (бер йөз унөч) кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 113 (бер йөз унөч) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2026 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү. (Чишмәле Сап авылында чишмә ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

2) Коеларны төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Чишмәле Сап авылында коены ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

Сез, 2024 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын, түбәндәге җирле сорауларны чишүгә юнәлтергә ризамы:

3) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

(Чишмәле Сап авылында һәйкәл территориясен яшелләндерү (яшел утыртмалар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); (Чишмәле Сап авылы балалар мәйданчыгын төзкләндерү (җиһазлар, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); Чишмәле Сап авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү))

мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.